Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы

# DARELFӨNYN
УНИВЕРСИТЕТ

12+

№12 (63)

11 апрель 2013 ел

## • Вакыйгалар эзеннән

А.М.Бутлеров ис. Химия институтының V курс студентлары **ЮРИЙ КУЗИН** һәм **РУСЛАН НАГРИМАНОВ** VII Бөтенроссия химия һәм наноматериаллар буенча **«МЕНДЕЛЕЕВ-2013»** яшь галимнәр, аспирантлар һәм студентлар **КОНФЕРЕНЦИЯСЕННӘН ЖИҢҮ БЕЛӘН КАЙТТЫ**. Санкт-Петербург дәүләт университеты базасында узган фәнни форумда чыгыш ясап, Ю.Кузин (фәнни жит. – проф. Г.А.Евтюгин) «Телдән ясалган иң яхшы доклад», Р.Нагриманов (фәнни жит. – доц. М.А.Варфоломеев) «Иң яхшы стенд доклады» өчен дипломнар белән бүләкләнде.

• • • •

6 апрель көнне **ХИСАПЛАУ МАТЕМАТИКАСЫ ҺӘМ МӘГЪЛҮМАТИ ТЕХНОЛОГИЯЛӘР ИНСТИТУТЫ ҮЗЕНЕҢ 35 ЯШЬЛЕК ЮБИЛЕЕН** билгеләде. Чара бик тантаналы рәвештә – Язгы балл формасында узды. Анда студентлар да, мөгаллимнәр дә теләп катнашты. Бәйрәм математикларның бик иҗади кешеләр икәнен тагын бер кат дәлилләде.

• • • •

**6-7 АПРЕЛЬ КӨННӘРЕНДӘ** Е.А.Боратынский музеенда «Михаил Муравьев һәм ул яшәгән заман. Өч шагыйрь: Гаврииил Державин, Николай Львов һәм Михаил Муравьевны Союзга тәкъдим итү» **IV БӨТЕНРОССИЯ ФӘННИ-ГАМӘЛИ КОНФЕРЕНЦИЯСЕ УЗДЫ**. Чараны оештыручылар арасында Филология һәм сәнгать институты да бар. Сургут, Ельц, Саратовтан килгән кунаклар, институтның рус әдәбияты тарихы кафедрасы студент-аспирантлары, укытучылар XVIII гасыр рус әдәбияты проблемаларын һәм аларның XIX-XX гасыр әдипләренең иҗатында чагылышын тикшерделәр.

• • • •

8 апрель көнне Филология һәм сәнгать институтында «Инглиз телен укытуда инновацияләр: методлар, бәяләү, теорияләр» **ХАЛЫКАРА МӘКТӘП-СЕМИНАР ҮЗ ЭШЕН БАШЛАП ЖИБӘРДЕ**. Чарада Америка белгечләре, ТРның мәктәп-гимназия, урта һәм югары уку йорты инглиз теле укытучылары катнашты. Форумда катнашучылар үзләрен кызыксындырган сорауларга җавапны Америка белгечләре, Мәскәүнең чит телләрне укыту университеты мөгаллимнәре, Идел буе федераль округыннан укытучылар үткәргән мастер-классларда таба алды.

• • • •

8 апрель көнне КФУда тышкы элемтәләр буенча проректор **ЛИНАР ЛАТЫЙПОВ** Фулбрайт программасының Мәскәүдәге офисы директоры **ДЖОЭЛЬ ЭРИКСОН** житәкчелегендәге **АМЕРИКА КОЛЛЕДЖЫ ДИРЕКТОРЛАРЫ ДЕЛЕГАЦИЯСЕН КАБУЛ ИТТЕ**. Очрашу барышында хезмәттәшлек итү турында сөйләштеләр. Казан университеты күп еллар дәвамында Фулбрайт программасы белән даими рәвештә эшли. Америка делегациясе шулай ук Алабуга һәм Яр Чаллы институтлары, IT-лицей эшчәнлеге, Универсиада авылы белән танышты.

• • • •

12 апрельгә кадәр Физика институтының конференц-залында профессор **В.ПОЛЬШАКОВ** (М.В.Ломоносов ис. Фундаменталь медицина факультетының Магнитлы-резонанс томографиясе һәм спектроскопиясе үзәге) **БИО-ЯМР БУЕНЧА ЛЕКЦИЯ ҺӘМ СЕМИНАРЛАР ҮТКӘРӘ**. Алар 14:40-17:30 сәг. уза.

• • • •

Тарих Музееның күргәзмә залында **«ИЛҺАМ» ДИП ИСЕМЛӘНГӘН КҮРГӘЗМӘ АЧЫЛДЫ**. Анда уку йортыбызның берничә хезмәткәренең сәнгати фотосурәтләре белән таныша аласыз.

• • • •

**СТУДЕНТЛАР ЛИГАСЫ ЮЛ ЙӨРУ ЧЫГЫМНАРЫН КОМПЕНЦАЦИЯЛӘҮ** буенча **КОНКУРС ИГЪЛАН ИТТЕ**. Анда көндезге бүлектә укучы, имтихан сессиясе буенча академик бурычларсыз, җәмәгать, массакүләм-мәдәни, спорт эшләрендә актив булган студентларга катнашырга мөмкин. Гаризаны 14 апрельгә кадәр бирергә кирәк. Тулырак мәгълүматны ***yaliga.ru*** порталыннан табып була.

**Ахыры 2нче биттә.**



Tatar-inform

# Студентларның үз язы!

**Динә МӨХТӘСИПОВА,**
хәбәрче

8 апрель көнне «Пирамида» мәдәни-күңел ачу комплексында «Студентлар язы-2013» республика студентлар иҗаты ачык фестиваленең гала-концерты узды. Анда 2,5 меңнән артык студент җыелды.

Быел фестиваль алты юнәлеш: музыка, хореография, театр һәм оригиналь жанр, интеллектуаль юнәлеш һәм журналистика буенча уздырылды. Номинацияләрдә җиңүчеләрне эксперт советы билгеләде.

Катнашучыларны һәм кунакларны ТР яшьләр эшләре, спорт һәм туризм министры Рафис Борһанов сәламләп, аларга алдагы көннәрендә дә иҗади уңышлар теләде. Конкурста җиңүчеләрнең 15-20 майда Ульяновск шәһәрендә узачак Бөтенроссия «Студентлар язы»нда катнашачагын билгеләп үтте.

Чыгышлар тематика, стиль буенча да аерылып торды. Җиңү көненә багышланган номер күңел кылларын аеруча тибрәндерде. Мода театры чыгышы студентлар сәләтенең күпкырлы булуын күрсәтте. Фестивальдә тамашачылар да тик кенә утырып тормады, кыш озатуга бәйле үзенчәлекле флешмобта катнашты.

**«Хореография»** һәм **«Интеллектуаль яз»** номинацияләрендә **фестивальнең төп бүләге Казан федераль университетына** тапшырылды. Шулай ук безнең уку йорты **«Театр»** юнәлешендә дә **Гран-при** алды. **«Музыка»** юнәлешендә **Икътисад, идарә һәм хокук институты** җиңде, «Оригиналь жанр» номинациясендә – А.Н.Туполев ис. Казан тикшеренү техник университеты.

Вузларның кече төркемендә «Вуз программасы» номинациясендә 3-нче урынны Россия кооперация университетының Казан кооператив университеты яулады, 2 нче урынны – Идел буе дәүләт физик культура, спорт һәм туризм академиясе, 1 нче урынны – Түбән Кама химия-технология институты.

Әлеге номинациядә вузларның зур төркемендә 3нче урынны Казан дәүләт медицина университеты алды. 2нче – Казан милли тикшеренү технология университеты һәм Н.Э.Бауман ис. Казан дәүләт ветеринария медицинасы академиясе, 1нче урында – А.Н.Туполев исемендәге Казан тикшеренү техник университеты. Гран-прига Казан дәүләт энергетика университеты ия булды.

«Студентлар язы» XXI Республика фестиваленең абсолют җиңүчесен игълан итү кичәнең кульминациясе булды. Гомуми зачетта 3нче урынны – КДИУ, 2нче урынны – Казан милли тикшеренү технология университеты, 1нче урынны А.Н.Туполев исемендәге Казан тикшеренү техник университеты алды. КФУ «Студентлар язы – 2013» Республика фестиваленең Гран-при бүләгенә ия булды. Вуз диплом һәм статуэткадан кала MacBookка сертификат алды. Калган Гран-при бүләген алучылар да конкурс дипломнары һәм статуэткалары, кыйммәтле бүләкләргә сертификатлар белән бүләкләнде.

*Tatar-inform мәгълүматлары файдаланылды*

## • Фән дөньясында

# Фәнни үзәкнең нигезе КФУда!

**Алинә САДЫЙКОВА,**
хәбәрче

10 апрель көнне Россия Фәннәр Академиясе Казан Фәнни Үзәгенең гомуми җыелышы булды. Ул Президиум составын сайлау максатыннан оештырылды. Кандидатлар исемлегендә КФУ ректоры Илшат Гафуров та бар иде.

Җыелышта Президент Аппараты җитәкчесе урынбасары, Татарстан Республикасы Эчке сәясәт департаменты җитәкчесе А.Терентьев, ТР Фән һәм мәгариф министры урынбасары А.Поминов, ТР Фәннәр Академиясе президенты Ә.Мәҗһаров, ТР югары уку йортлары Ректорлар советы рәисе, КФУ ректоры И.Гафуров катнашты.

**Ахыры 2нче биттә.**



Алия Галимуллина фотосы

**• Вакыйгалар эзеннән**

4-7 апрель көннәрендә Самара дәүләт университеты базасында Спортны программалаштыру буенча Идел буе төбәкләренең **СТУДЕНТЛАР КОМАНДАЛАРЫНЫҢ III (XIV) АЧЫК ЧЕМПИОНАТЫ** узды. Ярышта катнашу өчен, 60 команда гариза биргән. КФУны Хисаплау математикасы һәм мәгълүмати технологияләр институтыннан ике команда тәкъдир итте. Равил Һадиев җитәкләгән команда (команда составында В.Белов, Р.Ибраһимов, Б.Саләхетдинов) III дәрәҗәдәге дипломга лаек булды.

• • • •

11 апрель көнне «УНИКС»та **«КИЛӘЧӘК РОССИЯ КАДРЛАРЫ»** исемле **ВАКАНСИЯ ЯРМИНКӘСЕ** уздырылды. Ул КФУның чыгарылыш һәм әле укый торган студентларын вакытлыча һәм даими эшкә урнаштурыга юнәлтелгән иде. Яшь белгечнең карьера көнендә «Проктер энд Гембл» ҖЧҖ, «Шлюмберже Лоджелко Инк», «ТрансТехСервис» ҖЧҖ Идарә итү компаниясе, «АК БАРС» ААҖ, «Фуджицу Сервисез» ААҖ һәм башка эре компанияләрнең эш бирүчеләре дә катнашты. Ярминкәгә килүчеләр эш бирүчеләр белән әңгәмә кору, төрле психологик тестлар үтү, консультацияләр алу мөмкинлегенә ия булдылар.

• • • •

11 апрель көнне КФУ төп бинасында Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы вәкиле **«ДӘҮЛӘТ МУНИЦИПАЛЬ ЭЛЕКТРОН ХЕЗМӘТЕ»** дигән темага **ЛЕКЦИЯ** укыды.

• • • •

12 апрельдә КФУга Люксембург университеты проректоры **ФРАНК ЛЕПРЕВО** килер дип көтелә. Аны Люксембург Бөек Герцоглыгының Россиядәге Гадәттән тыш һәм вәкаләтле вәкиле Пьер Ферринг озатып йөриячәк.

*kpfu.ru сайты материаллары файдаланылды.*

**• Белем баскычлары**

# «Шлюмберже» - мөмкинлекләр иле!

**Ләйсән ИСХАКОВА,**
Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институты



Диана Поварова фотосы

10 АПРЕЛЬ КӨННЕ КАРА АЛТЫН ҺӘМ ГАЗ ТЕХНОЛОГИЯЛӘРЕ ИНСТИТУТЫНДА «SCHLUMBERGER» («ШЛЮМБЕРЖЕ») КОМПАНИЯСЕ ВӘКИЛЛӘРЕ СТУДЕНТЛАР БЕЛӘН ОЧРАШУ ҮТКӘРДЕ.

Бүген әлеге халыкара оешма – нефть һәм газ промышленносте өчен технологияләр эшләү өлкәсендә дөньяда беренче урында. Аның төп штаб-квартиралары Хьюстон, Париж, Гаага шәһәрләрендә урнашкан. Узган гасырның 20 елларында абыйлы-энеле французлар – Конрад һәм Марсель Шлюмберже тарафыннан оештырылган компаниядә хәзер 140 төрле милләт вәкиле – барлыгы 118 мең хезмәткәр көч куя.

Очрашуда Кара алтын һәм газ технологияләре институты студентлары гына түгел, Н.И.Лобачевский ис. математика һәм механика, А.М. Бутлеров ис. Химия институтларыннан да студентлар катнашты. Моның төп сәбәбе: «Шлюмберже» компаниясе хезмәт урынына геологлардан тыш, барлык югары техник белеме булган белгечләрне дә ала. Әлеге оешмага эшкә урнашасы килгән кеше өчен тагын бер мөһим шарт: инглиз телен камил белү. Чарада «Шлюмберже» вәкилләре әлеге оешманың тарихы, хәзерге көндәге эшчәнлеге, хезмәт шартлары хакында тәфсилләп сөйләде. КДУның мехматын тәмамлап, «Шлюмберже»да эшли башлаган Антонина белән Дарья да очрашуда катнашучылар белән тәҗрибә урталашты.



«Шлюмберже» студентларга төрле стажировка программалары тәкъдим итә. Бу исә, сайлап алу конкурсында югары нәтиҗәләр күрсәткән студентлар практикаларын Россиянең нефть чыга торган урыннарында һәм «Шлюмберже»ның фәнни-тикшеренү, технология яки җитештерү үзәкләрендә үтә ала дигән сүз. Гадәттә, стажировка үтү өчен, дүртенче курсны тәмамлаган студентларны сайлап алалар. Аларга стажировка дәвамында хезмәт хакы түләнә. Кирәк булган очракта торак һәм юл билетлары белән тәэмин итү дә каралган. Стажер-студент билгеле бер хезмәт участогына җибәрелә һәм остазга беркетелә. Студент белгечләр җитәкчелегендә Шлюмберже»дагы реаль чолганышка кереп чума. Стажировканы уңышлы үткән студентлар, югары уку йортын тәмамлау белән, оешмага даими хезмәткә урнашу мөмкинлегенә ия. Шулай да «Шлюмберже» вәкилләре студентларны алдан кисәтеп куйды. Яхшы эш урыны, югары хезмәт хакы корбаннар сорый, чөнки эш шартлары төрлечә булырга мөмкин. Гадәттә, белгечләргә я бик салкында, я бик эсседә көч түгәргә туры килә. Оешманың чит илләрдә урнашкан үзәкләренә махсус тренингларга барган очракта да сәяхәт итү мөмкинлеге турында онытып торырга туры киләчәк, чөнки күпчелек очракта чит шәһәрне вертолет яки такси тәрәзәсеннән генә күреп була.

Очрашуга килгән студентлар менә шундый файдалы мәгълүмат белән танышты, «Шлюмберже»ның яңа мөмкинлекләр ачучы оешма икәнлегенә тагын бер кат инанды. Чара ахырында теләгән һәр кеше оешма вәкилләренә кызыксындырган сорауларын бирә алды.

**• Фән дөньясында**

# Фәнни үзәкнең нигезе КФУда!

**Башы 1нче биттә.**

Җыелышны ТР Фәннәр Академиясе әгъзасы **Александр Коновалов** ачып җибәрде. Башта ул көн тәртибенә куелган мәсьәләләр белән таныштырды. Чара ике өлештән торды: иртәнге һәм кичке утырыш. Өч комиссия оештырылган иде: мандат, редакцион һәм санау. Аларга фәнни үзәкнең һәр институты (алар бишәү) үз вәкилен тәкъдим иткән иде.

Иртәнге утырыш Россия Фәннәр Академиясе Казан Фәнни Үзәгенең рәисе, академик **Олег Синяшинның** 2008-2012 еллар аралыгында фәнни үзәкнең эшчәнлеге турында мәгълүмат бирүе белән башланды. Ул үзәкнең структурасы, биш ел эчендә булган үзгәрешләре, оештырылган чаралары, ирешкән уңышлары турында мәгълүмат җиткерде. Хезмәттәшлек турында сөйләгәндә, Казан университеты белән бәйләнешкә аерым басым ясады: «Быелның февраль аенда безнең стратегик партнер – КФУ белән килешү төзелде. Әлеге хезмәттәшлекнең әһәмияте шунда: Казан университеты тарихы – Казан фәне тарихы ул. Казан фәнни үзәгенең нигезе әлеге уку йортына барып тоташа. Шуңа күрә безгә хезмәттәшлек җепләрен ныгытырга, бергә эшләргә кирәк». Чыгышының ахырында **Олег Синяшин** киләчәккә оптимизм, өмет белән караву турында әйтте: «Безнең талантлы яшьләребез, заманча тенденцияләргә туры килә торган юнәлешләребез, партнерларыбыз бар. 956 хезмәткәребезнең 1/3 өлеше яшь буын вәкилләре булу – бик куанычлы. Шуңа күрә яшь хезмәткәрләребезне торак белән тәэмин итәргә тырышабыз. Мисал өчен, узган елны 17 гаиләне «түбәле иттек». Бүгенге көндә 88 фатирлы торак йорт төзелеп килә». Олег Синяшин чыгышыннан соң, фикер алышулар булды.

КФУ Фәнни Үзәк белән килешү нигезендә күп проектларны тормышка ашырачак. Ректор **Илшат Гафуров**, фән белән бергәләп шөгыльләнү өчен, университетның лаборатория һәм кафедраларын тәкъдим итте. «Бүген безгә хөкүмәткә проблемалы вакыйгаларны аңлатып бирә, авырлыкларны чишәргә ярдәм итә торган мәйданнар кирәк. Ул зарланудан гына гыйбарәт булып калмыйча, киңәш бирү формасын алсын иде. Шуңа күрә күптән түгел генә тәкъдим ителгән Фән буенча Совет булдыру идеясенә уңай карыйм. Без – республика эчендә бер-беребезгә конкурент. Әмма республика кысаларыннан чыгып киткәч, берләшеп эшләгән очракта гына башка фәнни оешмалар белән конкуренция алып бара алачакбыз», – диде И.Гафуров.


Президиум составына, **Илшат Гафуров** белән беррәттән, ТР Фәннәр Академиясе президенты **Әхмәт Мазһаров**, ведомстволар арасындагы суперкомпьютер үзәгенең Казан филиалы директоры **Александр Елизаров**, «Дәүләт гамәли оптика институты» ААҖнең фәнни-җитештерү берләшмәсе генераль директоры **Владимир Иванов** кандидатуралары да тәкъдим ителгән иде. Нәтиҗәдә, бу урынга КФУ ректоры **Илшат Гафуров** сайланды.

**• Бездә кунак бар**

# Студентлар – Иннополис хезмәткәрләре

**Алинә САДЫЙКОВА,**
хәбәрче

9 АПРЕЛЬ КӨННЕ КАЗАН УНИВЕРСИТЕТЫ БАРЛЫК ТЕЛӘЧҮЧЕЛӘР ӨЧЕН КАРНЕГИ-МЕЛЛОН (ПИТТСБУРГ, АКШ) УНИВЕРСИТЕТЫНЫҢ ПРОГРАММАЛАШТЫРЫЛГАН ТӘЭМИН ИТҮ ЭШКӘРТМӘСЕ БЕЛӘН ИДАРӘ ӨЛКӘСЕНДӘ ҺӨНӘРИ ОРИЕНТАЦИОН ПРОГРАММАЛАР ДИРЕКТОРЫ, МӘГЪЛҮМАТИ ТЕХНОЛОГИЯЛӘР ФАКУЛЬТЕТЫ ПРОФЕССОРЫ ДЭВИД ГАРЛАН БЕЛӘН ОЧРАШУ МӨМКИНЛЕГЕ ТУДЫРДЫ.



Липа Домашинская фотосы

Профессор Дэвид Гарланның чыгышы «Мәгълүмати технологияләр өлкәсендә магистр – программалар белән тәэмин итүгә җитәкчелеге»/«Master of Science in Information Technology – Software Engineering, MSIT-SE», «мәгълүмати технологияләр» фәнен укытуның үзенчәлекләре» исемле тулы бер курска багышланган иде. Әлеге программа индустриядә бераз эшләү тәҗрибәсе булган профессиональ программистларга йөз тотып төзелгән. Иннополис университеты аны 2013-2014 уку елында Карнеги-Меллон университеты белән берлектә гамәлгә ашырачак.

Иннополис университеты – Россиядә тулаем заманча мәгълүмати технологияләр белән эшли торган беренче университет. Аның төп максаты илебездәге инновацион индустрияне яңа сыйфатлы дәрәҗәгә күтәрү өчен, югары квалификацияле кадрлар әзерләүдән гыйбарәт. «Хезмәттәшлек итү өчен, без күп юнәлешләр тәкъдим итә алабыз. Бу программада катнашырга теләүчеләргә бөтен мөмкинлекләр дә тудырылган», – дип белдерде Иннополис университеты ректоры, профессор Александр Тормасов. Мисал өчен, быел беренче унбиш студент (алар инде Иннополис университеты хезмәткәрләре), «Мәгълүмати технологияләр өлкәсендә магистр – программалар белән тәэмин итүгә җитәкчелеге» юнәлешендә бер ел буе белем алачаклар. Нәтиҗәләр уңышлы булган очракта, студентлар ике магистр һәм Карнеги-Меллон университетының рәсми дипломын алачак. Александр Тармасов сүзләренчә, монда, беренче чиратта, инглиз телен аеруча яхшы белү төп шарт булып тора.

Дэвид Гарлан үз чыгышында Карнеги-Меллон университеты турында тулы мәгълүмат бирде һәм программаның асылы белән таныштырды: «Әлеге программа информатика, техник проектлау, иҗтимагый-гуманитар фәннәрне өйрәнүне һәм программалаштыру күнекмәләрен үстерүне күз алдында тота». Профессор фикеренчә, Карнеги-Меллон университеты әлеге эшчәнлекне алып бару өчен бик кулай урын һәм анда мөмкинлекләр бик күп.

Лекциягә килгән студентлар, аспирантлар, укытучы-профессорлар очрашу дәвамында кунак-профессорлар белән фикер алышты һәм, әлбәттә, кызыксындырган сорауларына җавап алды. КФУ студентлары да Карнеги-Меллон университетында иҗади мөмкинлекләрен күрсәтә алыр, дип ышанабыз.

● Тарих эзләреннән

# Беренче татар ректоры - кем ул?

Гыймаз Баһаветдин улы Баһаветдинов Казан дәүләт университеты тарихына беренче татар ректоры буларак кереп калган.

Ул 1897 елның 27 декабрендә Бондюг посёлогында (хәзерге Менделеев шәһәре) эшче гаиләсендә туа. 12 яшеннән әтисе эшләгән химия заводында 1917 елга кадәр эшли. Бу дәвердә Гыймазга эшче, хисапчы, химия товарлары житештерү буенча мастер вазифаларын башкарырга туры килә. 1917 елгы революциядән соң, ул партиягә керә һәм заводта һөнәри эшчәнлеген дәвам итә: Бондюг заводы яшьләр союзын оештыра, «Мөселман яшьләре тавышы» газетасы редколлегиясендә әгъза булып тора. 1918 елда Гыймаз Баһаветдиновны Вятка шәһәренең эшче кооперативлар һәм фабрика-заводлар комитетына делегат итеп сайлыйлар. Бирердә ул Вятка губернасының сәнәгать бүлеге мөдире итеп билгеләнә. Шул ук елны, авыру сәбәпле, Гыймаз кире Бондюгка кайтып китә. 1918 елда ул Алабуга шәһәре янындагы сугышларда катнаша, Көнчыгыш фронтының 2нче армия штабы сәяси бүлеге сәркатибе ярдәмчесе итеп билгеләнә. 1918-20 еларда исә, Казан шәһәре башкарма комитеты әгъзасы һәм юстиция бүлеге мөдире, кассацион трибунал рәисе булып тора. 1921-22 елларда ТАССРның юстиция халык комиссары, 1923-25тә прокурор вазифаларын башкара. 1923 елда Гыймаз Баһаветдинов Казан дәүләт университетының физика-математика факультетына читтән торып укырга керә. 1926-28 еелларда ТАССР Үзәк Башкарма Комитеты Президиумы рәисе урынбасары һәм секретаре, 1928-30 елларда – ТАССР Халык комиссарлары советы рәисе урынбасары, экне эшләр халык комиссары. Нинди генә хезмәт урынында кеч куймасын, кайсы гына вазифаны башкармасын, Гыймаз Баһаветдинов һәрвакыт ана гына хас ихады кутәренкелек, дәрт белән эшли.

1929 елдан ул – Казан дәүләт университетында фәнни хезмәткәр. Кечкенәдән, химия заводы лабораториясендә инженер-химикларга химикатлар бирер торганда ук, Гыймаз белемгә омтылыш белән янып яши. Ниһаять, максатына ирешә. 1930 елда ул КДУны тәмамлый һәм химик дипломы ала. Шул ук елның февралендә университетның физика-математика факультеты деканы урынбасары итеп билгеләнә. Шул ук елның 7 мартында Гыймаз Баһаветдинов Казан университеты ректоры урынбасары була, соңрак ректор хезмәтенә күчерелә. Ректор вазифасын ул 1930–1931 елларда башкара. Шул рәвешле әлеге шәхес университетыбыз ельязмасына беренче татар ректоры булып кереп кала.

30 елларда ул матбугатта актив басыла. Ни кызганыч, Сталинның 1937-38 елгы репрессия дулкыны Гыймаз Баһаветдиновны да читләтеп узмый: 1938 елның маенда ул атып үтерелә һәм 1957 елда гына аклана. Университетның беренче татар ректоры Казанда Бауман урамы, 45 йорт адресы буенча яшәгән.






● Хәйрия эше

# Әти-әниле үксез сабыйлар

**Илмир ВӘЛИЕВ,**
Математика һәм механика институты

Сүзем Дербышки бистәсендә урнашкан интернатта көн күрүче балалар турында. Математика һәм механика институтының күптәнгә традициясе бар. Без һәр елны Дербышкида урнашкан балалар йортына барып, андагы сабыйларның күңелләрен күреп, оныталмаслык бәйрәм оештырып кайтабыз. Быел да, 8 апрель көнне, институтыбызның социаль һәм тәрбия эшләре буенча директор урынбасары П.Г.Великанов, укытучыбыз Э.Ж.Хәсәенова житәкчелегендә бурычыбызны үтәп кайттык.

«Көннәр якты булсын өчен, йокы татлы булсын өчен,әникирәк».– дигән шигырь юлларын шул көннән бирле эчтән генә кабатлап йөрим. Чыннан да, әни янда булса, дөнья рәхәт, ләкин моның кадерен белмәүчеләр дә бар бит. Проблемага тирләчә карарга була. Янызыбыз да зур хөрмәткә лаек, олы йөрәкле, безне яратучы әниләр бар, шуңа күрә без бик бәхетле. Кызганычка каршы, бу бәхеттән мәхрүм балалар да аз түгел. Бу очракта сүз кәеф-сафа коруны барыннан да өстен куеп, бала тәрияләүне зур мәшәкать, авыр йөккә санаган әти-әниләр турында. Нәтиҗәдә балалар йортлары, алар белән бергә ятим сабыйлар саны елдан-ел арта. Дербышки интернатында да ике йөзгә якын бала исәпләнә.

Интернат капкаларын ачуга, тәрәзә шакып, сәлам бирүче балаларны күрү тәэсирләрен гади сүзләр белән генә аңлатып булмый. Алар һәр кешене шулай каршы ала икән. Нарасыйлар кем килсә дә, нәрсә алып килсә дә сөенә. Аларга, бүләктән бигрәк, жылы караш, наз, ягымлы сүз, ана кочагы житми. Без, үз чиратыбызда, балаларга карата игътибарлы, назлы булырга тырыштык. Алар өчен кызыклы тамаша оештырдык: әкиятләрдән өзекләр, мавыктыргыч уеннар, жыр-бию балаларның актив катнашуы белән үрелеп барды. Һәркем үз сәләтен күрсәтергә ашыкты. Кемдер матур итеп рәсем ясый, кемдер оста итеп бии... Безнең чыгышларны карап, шаярышып утырдылар. Күзләрендә шатлык чаткылары яна башлаган сыман тоелды. Алып килгән бүләкләргә дә сөенеп туймадылар. Бәхетле мизгелләр тиз узса да, балалар күңелендә озак сакланыр, дип уйлыйм.

Анда барып кайткач, әтиәниеңнең, тормышның һәм сәламәтлегеңнең кадерен ныграк аңлый башлыйсың икән. Алардан да мөһимрәк әйбер булмавына кат-кат төшенәсең. Интернаттагы һәр сабый үз гаиләсе белән үз өендә, тормышның һәр көненә, һәр мизгеленә сөенеп яшәсен иде дә бит...



● Тарих сәхифәләреннән

***1953:***

7 апрельдә XIII Университет спартакиадасына нәтиҗәләр ясала: I урын – физика-математика факультеты, II урын – тарих-филология факультеты, III урын – геология факультеты.

***1963:***

5 апрельдә География факультеты деканы вазифасына доцент А.П.Депков билгеләнә.

12 апрельдә Университетның роман-герман телләре кафедрасына нигез салына.

13 апрельдә, Югары һәм махсус урта белем бирү министрлыгы боерыгы нигезендә, Университетта үсемлекләрне систематлаштыру һәм геоботаника, икътисади география һәм физика географиясе кафедралары берләштерелә.

***1983:***

13 апрельдә География факультеты деканы вазифасына Ю.П.Переведенцев билгеләнә.

14 апрельдә СССРның Югары һәм махсус урта белем бирү министрлыгы боерыгы белән, Югары уку йортларының ректорлар советы турындагы нигезләмә раслана.

***2003:***

11 апрельдә, уку барышының нәтиҗәлелеген арттыру максатыннан, КДУның Яр Чаллыдагы филиалында уку-укыту-методика бүлеге оештырыла.

● 12 апрель – Космонавтика көне


# «Гагарин кайтканмы әллә?»

**Нурсөя МИНЗИНА,**
татар филологиясе бүлеге

Бик көттереп, зарыктырып булса да, яз килеп итте, бугай. Күңелем язгы һавага сусаган булган икән: жиһанны кочасы, күләсе, шаярасы килә башлады.

Шаяру дигәннән, җае да чыгып куйды. Һәркем белә: 12 апрельдә авиация һәм космонавтика көнен билгеләп үтәбез. Шул бәйрәм уңаеннан, социаль челтәрдә студентлар арасында гадәти булмаган сораштыру үткәрергә уйладым.

Мәсьәләгә традицион булмаган ысул белән якын килергә булдым. «Ул язгы иртәдә ракета белән 1 сәгать 48 минутта, бөтен жир шарын әйләнеп, Саратов өлкәсенә төшеп утыра», – дигән жөмләне респондентларыма яздым һәм аларның бу жөмләгә карата фикерләре белән кызыксындым. Жавап бирүчеләрнең күбесе сораштыруда катнашканнарын аңламый да калдылар, ахры. Нәтиҗәдә ни килеп чыкканын, жавапларны беләсегез киләме? Алайса, киттек!




Кемдер язгы иртәдә ракетада, 1сәгать тә 48 минут эчендә бөтен жир шарын әйләнеп чыккан да Саратов өлкәсенә утырган. Дөресме?

Кем соң ул, кайда? ☺

Вакытым юк килде-китте әйберләр язарга!!!

Вот молодец ул! Мин аңламадым? ☺

Гагарин кайтканмы әллә? ☺

Бик молодец кеше! Минем кебек кызу кеше икәне күренеп тора! Ни өчен Казанга түгел, ә Саратов өлкәсенә төшүе генә аңлашылып бетми...

Без аны сагынып көттек!

Бу, әлбәттә, 12 апрель көнне беренче тапкыр галәмгә очкан кеше – Юрий Гагарин турында!

Миңа калса, моны белеп хыялыйрак кеше язган. Чөнки ракета белән жир шарын әйләнеп чыгу реаль түгел кебек. Ракетада оча торган кешеләр, минемчә, чыдам, бик көчле рухлы. Һәркем дә мондый адымга бара алмас иде. Шунысы игътибарны жәлеп итә: очучының кайчан һәм кайсы вакыт жиһанда булуы билгеле.

Бер түгел, ике әйләнсен! Минем анда ни эшем бар?!

Менә шундыйрак жаваплар алдым. Күрүебезчә, кемнеңдер кәефе булмаган, ә кемдер минем кебек уенга бирелеп, теләп язган. Белмәгәннәр белсеннәр: бу жөмлә Советлар Союзы гражданины Юрий Гагарин турында иде.

● Аклы-каралы дөнья

Китапларны сәяхәткә җибәрү турында ишеткәнең бармы? Ил буйлап түгел, әлбәттә, ә билгеле бер шәһәр, төбәк, район буенча. Юкны сөйләмә әле, диярге әшыкма! Хыял, теләк һәм максат булганда, күп әйберләрне тормышка ашырырга мөмкин бит.

# Китаплар да сәяхәт итә!

**Ләйсән ГАЛИУЛЛИНА,**
Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институты



### Китапка урын юк, дисәң

Барыбызга таныш булган вәзгыять: син күптән теләгән китабыңны сатып алдың, рәхәтләнеп укыдың һәм «тузан җыярга» шкафка тыгып куйдың. Ә нишләргә кала соң тагын – ташларга җәл, ә эчтәлеген инде яттан беләсең? Менә шундый очракларда күпләр хәзер «буккроссинг» дигән агымга кушыла икән. Аның асылы шунда: укып бетергән китапны буккроссерларның махсус сайтында теркисең, бирелә аңа билгеле номер бирелә. Шуны китапка ябыштырасың һәм «сәяхәткә» җибәрәсең.

Гадәттә мондый китапларны халык күп йөри торган җирләрдә яки «куркыныч булмаган урыннарда» табарга була. Әгәр сиңа шундый китапны эләктерү бәхете елмайса, сайтка кереп, әлеге китапка ябыштырылган номерны язып калдырырга кирәк булачак. Мондый алым ярдәмендә син кулыңа төшергән «белем чишмәсе»нең хуҗасы үз китабының кем кулында һәм кайсы шәһәрдә булганын белә ала. Шуны да онытма: китапны укып бетергәннән соң, аны яңадан кайдадыр калдырырга кирәк булачак. Буккроссерлык агымының мәгънәсе шуннан гыйбарәт – китап, кулдан-кулга күчеп, сәяхәт итәргә тиеш.

### Чишмә башы

Буккроссингны интернет-технологияләр белгече Рон Хорнбекер уйлап чыгара. Башта ул агымның асылын аңлата торган язуларны китаплар эченә тыгып, 20ләп «белем чишмәсе»н үз отеленең холлында калдырып китә. Ярты елдан соң, буккроссерлар саны инде 300 кешедән арткан була.

Бүген әлеге агым шактый популярлашкан. Россиядә, Италиядә, Франциядә, Америкада китапларын ирекле сәяхәткә җибәрүчеләр саны көннән-көн арта бара. Италиядә исә буккроссинг аеруча киң җәелгән. Биредә бу агымга хәтта зур дәрәҗәле кешеләр дә керешеп китә икән. Мәсәлән, Флоренция депутатлары буккроссерларга 4 меңгә якын китап бүләк иткәннәр. Шулай ук әлеге агымны популярлаштыруда журналистларның да роле зур. Италия радиостанцияләренең берсендә әлеге агымга багышланган аерым тапшыру да чыгып килә. Ә Америкадагы радио ди-джейлары бу агымны билгеле бер унга әйләндергәннәр. Эфирда табылган китапның коды һәм урыны әйтелә, ә буккроссер хуҗасыз китапны тапкан вакытта кичергән хисләре белән бүлешә.

### Казан чынбарлыгы

Казанда буккроссинг агымы әле туып кына килә. Көннәрнең берсендә, интернетта һәм басма матбугатта «Китапларны алыштыру» дигән белдерүләр күренә башлагач, кешеләр кызыксынып китә һәм шулай итеп буккроссингка нигез салына. «ВКонтакте» сайтында аның махсус төркеме дә булдырыла. Биредә булган китапларның исемлекләрен калдыралар, агымны популярлаштыруга бәйле фикерләрен җиткерәләр.

Зур-зур шәһәрләрдә буккроссинг дигән агым елдан-ел популярлаша. Мәскәүдә, Санкт-Петербургта китап сөючеләр саны бернинчә дистә мең. Ә Казанда буккроссинг белән мавыгучылар алай ук күп түгел. Сәбәбе нәрсәдә? Татарстанда буккроссингка реклама җитеп бетми. Мәсәлән, минем танышларым арасында да бик күп кеше китапларны яратып укый, әмма буккроссинг дигән сүзне ишеткәннәре юк. «Нәрсә соң ул?» – дип сорыйлар.

Бездә буккроссингның чәчәк атмавына кешедәге шикләнү хисе дә гаепле. Яхшы, кыйммәтле китапларны бар кеше дә «сәяхәткә» җибәрергә риза түгел. Шуңа да бездә әллә ни кызык булмаган, кирәксез китаплар белән генә «хушлаша»лар. Ә андыйларны укырга теләүчеләр дә аз шул.

Ә менә китапны кулга төшерү өчен «куркыныч булмаган урыннар»ны тәкъдим итүче Андрей Анисимов фикеренчә, башкалабызда буккроссинг озакламый бөтенләй бетәчәк. «Мондый юл белән китап уку хәзер кызык түгел инде. Кеше әкренләп электрон китапларга күчеп бара», – ди егет.

Мин дә буккросерлар рәтенә кердем әле. Бер китапны «сәяхәткә» җибәрдем һәм үзем дә бер кыздан укырга алдым. Кызык икән ул китаплар алмашу! Ә бәлки, безгә татар буккроссингын башлап җибәрергәдер?..

***P.S.** Казанда китапларны түбәндәге **«куркыныч булмаган урыннар»**дан алырга, калдырырга мөмкин:*

***«Амакс Сафар-отель»** кунакханәсе. Берьякны Гривка урамы, 1нче йорт;*

***«Книжный Двор»** кибете. Спартаковская урамы, 2 йорт.*

***ТРның Милли китапханәсе**. «Куркыныч булмаган» китап киштәләре китапханәнең Кремль урамындагы беренче бинасында, К.Маркс урамындагы икенче бинасында һәм Театральная урамындагы өченче бинасында бар.*

● Рульдә бичә

# Әй, машина, машина...

**Нәзирә ГЫЙЗЗӘТУЛЛИНА-МОСТАФИНА**

Әлеге язмам үз машиналарында укырга килүче студентлар һәм машиналы укытучылар өчен файдалы булыр, дип уйлыйм.

Шәһәр үзәгенә килдең исә, машинаңны кесәңә тыгып куясың килә башлый. Кая карасаң да, «туктап торырга ярамый», «машина куярга ярамый» дигән юл билгеләре эленеп тора. Ә көн саен эшкә йөрергә кирәк, җәмәгать. «Җәяү йөр!» диярсез сез. Өй белән эш арасы якын булса, бик рәхәтләнеп йөрер идем дә, шәһәр үзәгеннән ерак яшибез шул. Шуңа да, шәһәр эчендә машинада йөрүнең бөтен «тәмен татып» «рулит» итәргә кала.

Бөкедән тыш, машина йөртүчеләрнең тагын бер дошманы – чокыр-чакырлар. Шәһәребезнең кайбер урамнары яңа гына бомбага тоткан урыннарны хәтерләтә. Берез гына тизлегеңне арттырдың исә, тәгәрмәчсез, юк ла, машинасыз каласың. Иң куркыныч тагын бер «дошман»: камералар һәм эвакуаторлар. Камералар дигәннән, халык аларга ияләшә төште инде. ГИБДДдан бер-ике «сәлам хаты» алганнан соң, руль артында йөрүчеләр берберләренә антирадарлар бүләк итешләр. Кызганыч, ә менә эвакуаторлар белән көрәшүысуллары уйлап табылмаган әле...

Беркөн шулай өйгә кайту нияте белән эштән чыктым. Күрәм, машинадан җилләр искән. ГИБДДда эшләүче танышым минут эчендә машинаның Спартаковская урамындагы штрафстоянкада булуын хәбәр итте. Беренче эш итеп, штрафстоянкага барасы икән. Килеп җитү белән, эт оясы кадәр будкада синең кулыңа протокол тоттыралар. Шуның белән Оренбургский трактка җилдерәсең. ГИБДД кичке алтыга кадәр генә эшли, ягъни рөхсәт кәгазен бирә. Әгәр аны ала алмасаң, машина штрафстоянкада төн куна, кемнендер калын кесәсенә күп итеп акча тама. Билгеле инде, күбесенең машинасы стоянкада йоклап кала. Кеше кичке биштә-алтыда өйгә кайтырга кузгала, шул вакытта машинасының юклыгын күреп, аны эзләргә керешә. ГИБДД хезмәткәрләре дә вакытны махсус суза. Шул рөхсәт кәгазен язганда да дүрт-биш тапкыр каядыр чыгып керә. Кәгазьне кулыңа тоттыргач, теге эт оясына йөгерәсең.

Штрафстоянкадагы корылманы эт оясына охшатуымны, зинһар, гафу итә күрсеннәр – дөресе шул. Зурлыгы ике метрга ике метр. Халык күп, чөнки штрафстоянка көненә ике йөзләп машина кабул итә. Эвакуаторлар шәһәр үзәгендә бал кортлары кебек тыз-быз йөреп кенә тора. Протокол төзүче хезмәткәрнең язуы хастаханәдәге табиб язуын хәтерләтә. Шаһитлар табу да алар өчен проблема түгел, такси йөртүче егетләр ярдәмгә килә. Ә тегеләре, үз чиратында, таксистларга, юл читендә туктап, клиентлар көтәргә рөхсәт итәләр. Мескен хуҗа машинасын тиешле урынга куймаган өчен 1500 сум (кагыйдә бозуның нинди булуына карап, 1000нән 5000 сумга кадәр), эвакуатор хезмәте, машинасының штрафстоянкада саклануы өчен, матур гына сумма түли. Анары Казан шәһәренең тишек юллы урамнарыннан өенә таба юнәлә. Республика, ГИБДД җитәкчеләрен сүгеп, бер-бер артлы сораулар бирә: «Машиналарны кайда куярга?!», «Кайчан тигез, сыйфатлы юллардан йөрербез?!», «Без түләгән зур суммадагы штраф акчалары кая китә?!»



● Киңәш-табыш

# Имтиханга ничек әзерләнергә?

Киңәшче ролендә – **Ләйсән ИСХАКОВА**

Сессия дә килеп җитте. Ә син әле өзер түгел һәм нидән башларга белмисең? Димәк, киңәшләребез нәкъ синең өчен!



✔ Планлаштыр! Вакытыңны дөрес бүләргә өйрән. Буш вакытың булу белән, лекцияләреңне ал да укырга тотын!

✔ Ничек истә калдырырга? Еш кына шулай була: лекцияне укыйсың һәм инде 10 минуттан берни истә түгел. Моны булдырмас өчен, иң мөһим, кирәкле тоелган фикерләрне аерым дәфтәргә конспект рәвешендә теркәп бар. Язганда, күрү хәтере дә эшли. Язганнарыңны кычкырып уку исә тагын да яхшырак. Бу очракта ишетү хәтере дә эшкә җигелә.

✔ Имтиханны арган баштан бирү авыр, шуңа төне буе укып утырудан мәгънә булмаячак. Яхшылап ял ит!

✔ Имтихан иртәсе. Конспект турында хәтерлисеңме? Анда барысы да кыска һәм аңлаешлы итеп язылган. Әнә шул мәгълүматны тагын бер кат укып чык, чөнки иртән мәгълүмат әйбәтрәк үзләштерелә.

✔ Шпаргалка язу да файдага булачак. Әлбәттә, бу сине җаваплылыктан азат итми, барыбер укырга, өйрәнергә туры киләчәк. Шулай да, шпаргалка язганда, материалны тагын бер кат кабатлау мөмкинлеге туа.

✔ Әзерлекне иң авыр сораулардан башла. Укытучың, һичшиксез, белемеңне бәяләячәк!

✔ Үз-үзеңә ышаныч – уңыш чыганагы. Каушама, үзеңне тыныч тот. Юкса, сорауга җавапны белгән очракта да, уңышсызлыкка дучар булырга мөмкин.

Ни генә булмасын, әзерлекне соңгы көнгә калдырма. Һәр имтиханга җаваплы һәм җитди итеп әзерлән. Уңышлар!

DARELFØNYN УНИВЕРСИТЕТ
Тираж 1000
Газета бушлай таратыла

Баш мөхәррир - Илдар Азат улы Кәримов
Мөхәррир - Динара Равил кызы Миннекаева
Иҗат коллективы: А.Ю.Садыйкова
Корректор - Р.А.Асылгәрәева
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч - Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Профессор Нужин ур., 1/37 йорт, 318 каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 233-70-04.
Электрон почта: darelfonyn@mail.ru Сайт: kpfu.ru

Газета Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2012 елның 13 мартында ПИ № ТУ 16-00696 нчы таныклык белән теркәлде.
Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00
«Куранты» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Журналистлар ур., 1, 317 оф.